КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 423

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тимер юл һәм су транспорты өлкәсендә аерым чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1036 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тимер юл һәм су транспорты өлкәсендә аерым чараларны тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1036 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга тимер юл транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Шәһәр яны элемтәсендә су транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга су транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин